**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay.ispolkom@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак ав. **КАРАР**

«09» октября 2025 ел. № 353

Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибенең Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 25.04.2018 елның 184- нче карарына «Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибен раслау турында» үзгәрешләр кертү турында

2006 елның 03 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон «Автоном учреждениеләр турында» нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ**:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибен раслау турында" 25.04.2018 елның 184-нче Карары белән расланган Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, аларның төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктта «яисә бүлеп бирү» сүзләрен «бүлеп бирү һәм үзгәртеп кору»сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлдәге дәүләт яисә муниципаль учреждение тибын үзгәртү юлы белән Автоном учреждение төзү турындагы карар, әгәр мондый карар гражданнарның конституциячел хокукларын, шул исәптән түләүсез белем алу хокукын, мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәни кыйммәтләрдән файдалану хокукын, сәламәтлекне саклау һәм түләүсез медицина ярдәмен бозуга китермәсә, дәүләт яисә муниципаль учреждение инициативасы буенча аларның ризалыгы белән кабул ителә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы С.Н.Балакирев

Баш. Самарина О.К.
8(84346)20051